ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяда:
а) «Дәүләт» сүзен «1. Дәүләт» сүзләренә алмаштырырга;
б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:
«2. Татарстан Республикасы Нотариаль палатасы нотариуслар эшчәнлеге барышында барлыкка килгән нотариаль документларны саклау, туплау, исәпкә алу һәм алардан файдалану өчен нотариаль архив булдырырга тиеш.»;

2) 18 статьяда:
а) исемендә «гражданнарның» сүзеннән соң «, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариусларның» сүзләрен өстәргә;
б) 1 өлештә «гражданнар» сүзеннән соң «, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариуслар» сүзләрен өстәргә;

3) 19 статьяда:
а) исемендә «, нотариаль документларны саклау» сүзләрен өстәргә;
б) түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:
«4. Нотариаль документларны саклау Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

4) 22 статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:
«$2^1$. Дәүләт архивлары һәм муниципаль архивлар, үзләрендә тиешле архив документлары булганда, Россия Федерациясе Пенсия иминияте һәм социаль

иминият фонды гарызнамәсе буенча, «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, граждан турында аны пенсия белән тәэмин итү өчен кирәкле белешмәләрне бирәләр.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктыннан тыш, 2023 елның 11 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пункты 2023 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2022 ел, 26 декабрь
№ 106-ТРЗ